РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

20 май 2020 ел №13

Кукмара муниципаль районы Башкарма
комитетына Кукмара муниципаль районы
Кукмара шәһәре Башкарма комитеты
вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советына Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

- җирлекнең генераль планын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, территорияне планлаштыру буенча җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән документларны раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәтләр (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлаштыру җирле нормативларын раслау, муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендә җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен алу, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында рекомендацияләр бирү, планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә, планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкин түгеллеге турында хәбәрнамә, авыл җирлекләре территорияләрендә

урнашкан җир кишәрлекләрендә төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектының шәхси торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрү, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар, законсыз төзелгән корылманы сүтү яки аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү, реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документлар яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән чик параметрларына туры китерү (алга таба шулай ук – билгеләнгән таләпләргә туры китерү) турында карар, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу турында карар кабул итү, рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтүне яисә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетына түбәндәгеләрне башкарырга:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, бюджет законнары нигезендә Кукмара муниципаль районы Советының 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре бюджеты турында карарга үзгәрешләр кертү турында карары проектын эшләргә һәм карау өчен тәкъдим итәргә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына, Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Нотфуллинга йөкләргә.

Кукмара шәһәре Мэры С. Д. Димитриев